**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның 15 ноябре № 104**

**2018 елның 28 апрелендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 78 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**
*(Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2018 елның 7 июнендәге 85 номерлы Карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)*

2018 елның 28 мартындагы “Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисләренә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында”гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 182 нче Карарына үзгәрешләр кертү хакында”гы 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2018 елның 28 апрелендәге “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 78 номерлы карарына *(Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2018 елның 7 июнендәге 85 номерлы Карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)* түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) “Җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайлау, вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү” 2нче булегенең 1 пунктының бишенче абзацындагы “4,65” саннарын “6,72” саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге Карар 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” рәсми сайтының мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Яңасала авыл җирлеге Башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Яңасала авыл җирлеге**
**Советы Рәисе** **И.Х. Шиһабиев**